| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 07.12.2022 | г. Казань | № 699-133/тэ-2022 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 25 маендагы 50-2/тэ-2022 номерлы, «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 25 маендагы 57-9/тэ-2022 номерлы карарлары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 7 декабрендәге 42-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Казэнерго» акционерлык җәмгыятеннән җылы белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү хакында» 18.12.2018 № 5-96/тэ

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2018 № 5-96/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында» 11.12.2019 № 5-103/тэ;

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2018 № 5-96/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2020 № 452-88/тэ-2020;

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2018 № 5-96/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында» 07.12.2021 № 457-97/тэ-2021.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев